КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 апрель г.Казань № 285

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативларының эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап формаларын раслау турында» 2018 ел, 19 апрель, 268 нче карары белән расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативларының эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап формаларын раслау турында» 2018 ел, 19 апрель, 268 нче карары

белән расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасына җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасына кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасына кушымта

Форма

Муниципаль берәмлек территориясендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзелә торган объектлар турында мәгълүматлар

___________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
_______ квартал ______ ел

<table>
<tr><th rowspan="2">Т/с</th><th rowspan="2">Төзүченең тулы (фирма) һәм кыскартылган исеме, урнашу урыны, ИНН, төзүченең рәсми сайты</th><th rowspan="2">Күчемсез милек объектының исеме (функциональ билгеләнеше, катлар саны), күчемсез милек объектының урнашу урыны (төзелеш адресы), төзелешне рөхсәт итү турында мәгълүмат (№ , бирү датасы, кем тарафыннан бирелгән, гамәлдә булу срогы), объектны файдалануга тапшыру өчен планлаштырылган рөхсәт алу вакыты</th><th rowspan="2">Объектның гомуми мәйданы, шул исәптән торак мәйданы</th><th rowspan="2">Планлаштырылган төзелеш бәясе, млн.сум</th><th rowspan="2">Төзелеш проектын тормышка ашыруның якынча графигын үтәү: (үтәлә/ үтәлми)</th><th rowspan="2">Төзелеш өчен бирелгән (дәүләт теркәү номеры, теркәлү датасы) җир кишәрлегенә милекченең теркәлгән хокукы / аренда хокукы турында мәгълүмат)</th><th rowspan="2">Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында бирелгән проект декларациясе номеры</th><th rowspan="2">Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү формасы (исәп-хисап счеты / эскроу счеты)</th><th colspan="2">Төзүченең исәп-хисап счеты ачылган вәкаләтле банк</th><th colspan="2">Өлешле төзелештә катнашучы эскроу счетлары ачык булырга тиеш банк</th><th colspan="3">Өлешле төзелештә катнашу килешүләре төзелә ала торган күчемсез милек объекты составында мөстәкыйль өлешләрнең гомуми саны</th><th colspan="3">Күчемсез милек объекты буенча өлешле төзелештә катнашу килешүләре турында мәгълүмат</th><th colspan="2">Өлешле төзелеш объектларын өлешле төзелештә катнашучыларга тапшыру вакыты</th><th>Объектны файдалануга тапшырырга рөхсәт итү турында мәгълүмат (№, бирү датасы, кем тарафыннан бирелгән)</th></tr>
<tr><th>төзүченең исәп-хисап счеты ачылган вәкаләтле банкның оештыру-хокукый форма һәм исеме (вәкаләтле банкның кыскартылган исеме)</th><th>вәкаләтле банкта төзүченең исәп-хисап счеты реквизитлары (исәп-хисап счеты номеры, корреспондент счеты, БИК, ИНН / КПП, ОГРН, ОКПО)</th><th>өлешләп төзүдә катнашучылар тарафыннан эскроу счеты ачык булырга тиеш кредит оешмасының оештыру-хокукый форма һәм тулы исеме</th><th>кредит оешмасының салым түләүчесе шәхси номеры, анда өлешләп төзүдә катнашучылар эскроу счетлар ачарга тиеш</th><th>фатирлар</th><th>торак булмаган бүлмәләр</th><th>машина-урын</th><th>беренче килешүне теркәү датасы</th><th>төзелеш башланганнан бирле төзелгән килешүләрнең гомуми саны</th><th>килешүләр буенча йөкләмәләрнең гомуми суммасы, млн. сум</th><th>килешүдә каралган</th><th>үзгәрешләр (өстәмә килешү белән каралган)».</th><th></th></tr>
</table>

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин